ХӘТЕР МӘҢГЕЛЕК
Чувашиядә тыл хезмәтчәннәренә багышланган мемориал ачылды
> 2

ОЧТЫ, ОЧТЫ...
Кешегә билгесез саналган объектлар (НЛО) чынлан да бармы, реальме?
> 2

НОМЕРДА – ДОКУМЕНТ
Татарстан Президенты имзалаган яңа законнар
> 3

ЯҢА СӘХИФӘ
Кучтәначка – ял бите
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 93 (28866) | Шимбә | 2 июль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

СОҢ БУЛСА ДА, УҢ БУЛДЫ

Печән өсте

«Печән быел мулдан, үзебез чыдыйк та, техника гына түзсен. Җыеп алырлык көне дә булсын». Бүген печән өстендә армый-талмый тир түгүче халыкның кәефе әнә шундый. Сала кешесе өчен бик җаваплы, мәшәкатьле, борчулы, шул ук вакытта күңелле дә чор. Авылда яшәүчеләр терлекләренә кыш чыгарга җитәрлек азык әзерләп бетергәч кенә иркен сулыш алып куя ала. Быел җәй сузылыбрак килгәнлектән, печән дә соңрак өлгерде. Кайсыдыр районнарда эш гөрләсә, кайдадыр, әле иртәрәк дип, сабыр итеп торалар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Азнакай районының Митрәй авылында яшәүче Әхмәдишиннар гаиләсе малларны күпләп асрый. Аларның сөтлебикәләре генә дә бишәү. Үгезләре, бозаулары, кош-кортлары да шактый. Димәк, ашату ягын яхшылап хәстәрләргә кирәк.

– Соңгы атна-ун көндә гаиләбез белән болында без. Эштән кайтабыз да печән хәстәрләргә йөгерәбез. Әле менә бүген дә печән бушатып яткан вакытка туры килдегез, – диде Рушания Әхмәдишина. – Быел печән мулдан. Чабып, җыеп кына өлгер. Тракторлар гына чыдасын инде, дип эшлибез. Сатып алырга туры килмәс, дип сөенәбез. Узган ел 60лап түкне сатып алган идек. Быел үз көчебез белән җитәрлек әзерләргә дип тырышабыз.

Хуҗабикә әйтүенчә, авыл тирәсендә печәнлекләр күп. Кайсын трактор арбасына төяп кайтарсалар, кайсын түкләп куялар икән.

– Тырышмасаң, берни дә булмый. Мондый мәшәкать – вакытлы гына ул. Авырткан урыннарга укол кадыйбыз да алга таба йөгерәбез. Аның каравы җәен тырышып эшләгәч, кышын күңел тыныч, – дип елмая Рушания Әхмәдишина.

Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында да халык малны күп асрый. Тау асты Тәкермәне белән бергә 400ләп баш терлек тоталар. Ләкин печәнне халыкның күпчелеге фермерлардан, эре хуҗалыклардан сатып ала.

– Бездә электән үк печән чабарлык болыннар булмады. Колхозлар чорында халыкка печәнне бүлеп биреш иде. Алар таралгач, фермерлар, инвесторлардан сатып алырга ияләштек. Дөрес, кулында техникасы булган халык үзе дә чабып әзерләргә тырыша. Печән бик әйбәт. Иренмәгән кешегә рәхәтләнеп, күкрәк киереп әзерләрлек.

Әлки районында халык ныклап торып печән чабуга керешмәгән әле.

– Кулында техникасы булган кешеләр бүленми торган болыннарга төшкәли башлады инде, – диде Карга авыл җирлеге башлыгы Рамил Минһаҗев. – Мин әле дә иске тәртип буенча эшлим. Печән чоры җитә башласа, дүрт-биш кеше белән болыннарны карап чыгабыз. Шуннан соң клубка җыелып, жирәбә салабыз. Мәсәлән, бер территориягә ун кешене билгелибез дә, алар үзара килешеп, өлешенә тигән көмешен чабып ала. Үлән чабып ала торган шундый өч-дүрт мәйданыбыз бар.

Хәер, монда халыкның печән каян табыйм икән дип, баш авырттырганы юк. Быел аеруча уңды бит.

– Капка төбеннән үк калын үлән үсә быел! Чап та ал. Тик без, ныклап, Корбан бәйрәмнәрен уздырып җибәргәч тотынырбыз дип торабыз. Чөнки 20 көнгә соңрак өлгерде бит. 9 май тирәсендә яңа күтәрелә генә башлады, әле яшь, сусыл ул. Халык та сабыр итә. Инде хәзер печән җыеп алырлык көннәр булуын телибез, – диде ул.

Арча районының Корайван авылы фермеры Фәнис Әхмәтханов та, без шалтыратканда, терлекләргә сенаж хәстәрләп йөри иде. 60 баш малга җитәрлек ризык юнәтеп өлгертергә кирәк бит. Үзеннән артканын халыкка да сатарга нияте бар.

– Печәнне чаба башладык, инде хәзер җиллэтеп, яхшылап киптерәсе бар. Ныклап торып берничә көннән генә кузгалабыз. Узган елларны да шушы тирәләрдә әзерләргә тотына идек. Быел эшне соңрак башладык дип әйтеп булмый, – диде фермер.

Печән бәяләренә килгәндә, әлегә күпчелек районнарда аларның хакларын әйтеп бирә алмадылар. Быел үлән мулдан булганга күрә, узган ел белән чагыштырганда, бәяләре арзанрак булырга мөмкин, диделәр. Мәсәлән, Минзәлә районында 5 центнерлы түкләрне 1200–1500 сумга тәкъдим итә башлаганнар.

Бүген эре хуҗалыкларның да төп мәшәкате – терлек азыгы әзерләү. Республика Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының оператив мәгълүматларына караганда, Татарстанда 273596 гектардан күпьеллык үләннәр җыеп алынган. Шуларның 81775 гектары – печән, 182882 гектары – сенаж, 8939ы – яшел азык. Бу – барлык мәйданның 72 проценты дигән сүз. Бу юнәлештә Актаныш, Әтнә, Балтач, Кукмара, Арча районнары аграрийлары аеруча яхшы эшли.

Чикләүләр бетерелә

Роспотребнадзор ковидка каршы барлык чикләүләрне алган. Битлек кию, төнге сәгатьләрдә кафе-рестораннарны эшләтмәү кебек тыюлар узганда кала дигән сүз. Ләкин хәлләр начараеп киткән очракта чикләүләр кабат кертелергә мөмкин.

Ведомствоның матбугат хезмәте хәбәренә караганда, соңгы дүрт айда Россиядә чирнең бик нык чигенүе күзәтелә. Бер атна эчендә авыру йоктыручылар саны пандемия чорындагыга караганда 64 тапкырдан күбрәккә кимегән. Инфекция йөртүчеләрнең асылда барысы да диярлек (93 проценты) чирне җиңелчә кичерә. Чир нигездә суык тидерү кебек кенә уза. Роспотребнадзорның фәнни оешмалары белгечләре әйтүенчә, гомумән, җәйге айларда «омикрон» штаммының көчәеп китү ихтималы юк дәрәҗәсендә.

Чикләүләрнең 1 марттан алына башлавын искә төшерик. Чирләүчеләр саны кимүгә һәм «омикрон»ның җиңелрәк кичерелүе ачыклануга бәйле булды бу.

Юл төзелешенә өстәмә акча

«Мәскәү – Түбән Новгород – Казан» М12 юлын төзүне тизләтү өчен федераль бюджеттан тагын 28 миллиард сум бирелә. Бу трассаның төрле төбәкләрдәге өлешләрен вакытыннан алда файдалануга тапшыру мөмкинлеге ачачак. Өстәмә акчаның проектны киләсе елда төзеп бетерүгә ярдәм итәчәге күздә тотыла.

Түләүле яңа юл «Европа – Көнбатыш Кытай» халыкара юлының бер өлешенә әйләнәчәк. Ул Мәскәү, Владимир, Свердловск, Түбән Новгород, Төмән, Чиләбе өлкәләре, шулай ук Татарстан һәм Чувашия аша уза. Тиз йөрешле трасса Санкт-Петербургтан Екатеринбургка кадәр 2 мең чакрымнан артыграк юлны бернинди светофорсыз үтү мөмкинлеге бирәчәк. Юлның Мәскәүдән Владимир өлкәсенә кадәр 49 чакрым аралыктагы өлеше инде бу елның ахырында ук сынау режимында «эшли» башлаячак.

Маршрут үзгәрә

Казанда трамвай маршрутлары үзгәрә. Яңа 4 маршрут барлыкка киләчәк, трамвайлар саны 85тән 88гә җитәчәк, ә юлларының гомуми озынлыгы 1,5 тапкыр диярлек артып, 247 чакрымга тулачак (моңарчы 146 чакрым иде). Үзгәрешләр 4 нче («Халитов урамы» – «9 нчы микрорайон») һәм 6 нчы («Каравай бистәсе» – «Халитов урамы») маршрутлардан тыш, барлык маршрутларга кагыла.

1 нче маршрут («Химическая урамы – тимер юл вокзалы») икегә бүленә. Кеше күп йөрми торган өлешенә – Химическая урамыннан Каравай бистәсенә кадәр яңа – 8 нче маршрут кертелә. Ә 1 нче маршрут үзе Каравай бистәсеннән Елга портына кадәр сузыла.

7 нче маршрут трамвайлары тимер юл вокзалыннан Глазунов урамына кадәр – Ямашев һәм Җиңү проспектлары аша, 3 нче маршрутныкы шул ук тимер юл вокзалыннан Глазунов урамына кадәр – Тукай урамы аша йөреячәк. Бoҗра – 5 нче һәм 5а маршрутлары үзгәрешсез кала.

kzn.ru

Ничек һөнәр сайларга?

Әти-әни кушканга түгел

Киләсе биш елда мәгълүмат технологияләре, робот техникасы өлкәсендәге белгечләргә ихтыяҗ зур булачак. Шулай ук химия, энергетика, төзелеш өлкәсендә дә эшче кулларга сорау бар.

Һөнәр сайлаганда, әти-әниләр балаларына үз фикерләрен тагарга тиешме? Укырга керә алмаган очракта нишләргә? Әти-әниләр арасында узган интернет-җыелышта белгечләр көн кадагындагы сорауларга җавап бирде.

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының кадрларны һөнәри яктан әзерләү бүлеге җитәкчесе Софья Тонконог республиканың хезмәт базарындагы вазгыять белән таныштырды. Ел саен 23–27 мең яшь белгечнең тәкъдим ителгән эш урыннарына килүе мөһим. Җиде елга фаразлар шундыйрак. Бигрәк тә урта һөнәри уку йортларын тәмамлаган яшьләрне бишкуллап көтәләр. Андыйлар эш таба алмыйча аптырап йөрмәячәк. 2023 елда – 10 мең, 2027 елда 18 мең гади белгеч кирәк. Югары белем буенча саннар исә башкачарак. Хезмәт базарына ел саен уртача 4500–5600 «ак яка» килсә дә җитә. Әйтик, 2023 елда – вуз тәмамлаган 5600, 2029 елда 3800 белгеч кирәк дип фаразлана. Чыгарылыш сыйныф укучылары, һөнәр сайлаганда, менә шушы саннарга да игътибар итсен иде. Башлангыч һөнәри белем дигәндә, химия, төзелеш, энергетика өлкәсендә монтажчылар, контролер, техникларга кытлык бар. Бу белгечләргә яхшы хезмәт хакы да вәгъдә итәләр. Шулай ук мәгълүмат системасы өлкәсендәге белгечләр дә иң кирәклеләрдән санала.

Әти-әниләр җыелышында катнашкан «Татарстан банкы» бүлегенең идарә җитәкчесе урынбасары Руслан Әхәтов робот техникасы өлкәсенә аерым тукталды. «Робототехника һәрвакыт өстәмә яңа һөнәрләр тудыра. Бу – конструктор, механик, оператор, оештыручы гына түгел, хәтта юристлар да. Алар хокукый мәсьәләләрне хәл итәр өчен кирәк. Бүген табибларга да, киберһөҗүмнәргә каршы торучы белгечләргә дә ихтыяҗ бар», – диде ул.

Җитәкче буларак, эшкә алганда яшьләрнең аралашу, үзеңне кулда тота белү, тәнкыйди фикерләү осталыкларына игътибар итә икән. Соңгысын арттыру өчен фантастик хикәяләр укырга киңәш итте. Белгеч билгеләп үткәнчә, яшьләргә сабырлык, кылган адымнар турында уйлау, үз хатаңны тану кебек нәрсәләр җитеп бетми. Әмма аларда эшкуарлыкка тартылу көчле. Яшьләргә бары ярдәм итәргә генә кирәк. Эшкә урнашырга барганда исә тышкы кыяфәтнең пөхтә булырга тиешлеген һәм бер минутка да соңга калырга ярамавын искәртте. Һөнәр сайларга өлгермәгәннәрне дә тынычландырды. Аның әйтүенчә, кеше гомер буе укый, яңа һөнәрләргә өйрәнә. Дөрес сайламаганда, икенче белгечлеккә дә укырга була. «Мәсәлән, мин Суворов училищесын тәмамладым. Хәрби булырга тиеш идем. Аннан хокук белгечлегенә укыдым. Әмма мин банкир булып эшлим. Ягъни тормыш төрлечә борылырга мөмкин», – диде ул.

Чараны алып барган Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева исә республиканың югары уку йортларында иң кирәкле биш юнәлешне атады. Болар – икътисад һәм идарә итү, педагогик фәннәр, информатика һәм исәпләү техникасы, электр һәм җылылык энергетикасы, юриспруденция. «Һөнәрләр дә күп, чыгарылыш укучыларының сайлау мөмкинлеге дә зур. Быел мәктәпне 15 меңнән артык укучы тәмамлады», – диде Ләйлә Фазлыева.

Җыелышта сүз олы тормышка аяк басучы егет-кызларга һөнәр сайлауда булышу, психологик яктан ярдәм итү турында барды.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Ольга ВАСИЛЬЕВА, Россия Мәгариф академиясенең попечительләр советы рәисе:

Башлангыч мәктәпләрдә «туган тел», «җәмгыять белеме», «культурология», «гуманитар һәм иҗтимагый фәннәр» укыту методикасы буенча соңгы 10 елда бер генә диссертация дә язылмаган. Димәк, бездә кеше һәм гражданин тәрбияләү темасы игътибардан читтә калып килә.

(«Парламентская газета»дагы әңгәмәсеннән)

НӘРСӘДӘН БАШКА ТОРМЫШ ЮК?

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге Россиядә яшәүчеләргә әнә шул сорауны биргән. Башка еллар белән чагыштырганда, социаль челтәрләр, гаджет һәм компьютер уеннары халыкның көнкүреш гадәтләре бишлегеннән төшеп калган.



ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Очты, очты, тәлинкәләр очты...

Оча торган тәлинкәләр, яки конструкциясеннән башлап, кемнәр идарә иткәне, ни эшләп, нинди максатлар белән йөргәне безгә – кеше затларына аңлаешсыз, билгесез саналган объектлар (НЛО) чыннан да бармы, реальме? Әллә инде алар атмосферадагы оптик эффектлар, кемнеңдер күзенә күренгән галлюцинация, без аңламаган метеорологик яисә астрономик күренешләр генәме? Бүген, 2 июль – Бөтендөнья НЛО, башкача әйткәндә, Бөтендөнья уфологлар көне.

Кеше заты, үзен бик белдеклегә санаса, төрле фәннәрне алга әйдәүче галим-голәмәләребез күп булса да, ул үзен чолгап алган тирәлек, аның төзелеше, үзлекләре хакында әлегә ифрат та аз белә. Ерак галәмнәр яисә микродөнья турында әйткән дә юк. НЛО феномены хакында нидер сөйли алучылар булганда да, алар әйткән хакыйкатькә туры килмәскә дә мөмкин. Техник уңышлар белән мактанган, үзебезне әллә кемгә санаган җәһәттә дә, без, кешелек, шушы көнгәчә ирешкән үсеш, алгарышның шактый чамалы булуын, танып белү, акыл дигәндә чикләнгәнлегебезне әле тулысынча аңышмыйбыз. Акылыбыз җитми. Нәрсә ул акыл, дигәндә, галимнәр аны мәгълүматны кабул итү, анализлау һәм шуның нәтиҗәсендә яңа мәгълүмат тудыру сәләте, дип бәяли. Яңа туган нәтиҗә-мәгълүмат исә, үз чиратында, тагын да тирәнрәге, югарырак баскычта торганы яралуга җирлек булырга тиеш, ди алар. Тиештер, ләкин кешелек яулаган баскычлар әле санаулы гына...

НЛО темасына кайтканда, без искәрткән датаның, аның белән бергә уфологиянең кыска тарихының моннан нәкъ 75 ел элек булган вакыйгага барып тоташуы мәгълүм. Диск рәвешендәге ниндидер сәер очу аппаратының Американың тау-ташлы, чүлле Нью-Мексико штатында 1947 елның июль башындагы һәлакәтенә. Розуэлл атлы кечкенә шәһәр янында җиргә кадалган ул очкыч каян килеп чыккан, нишләп йөргән, кемнеке – билгесез. Һәлакәткә кагылышлы язма һәм фотоматериалларга тиз генә «үтә яшерен» грифы салынса да, газеталарга очу аппаратының гадәти булмаган конструкциясе, фән белмәгән металлдан эшләнгән корпусы, хәтта авария урыныннан кешегә охшаш җан ияләренең мәетләрен җыеп каядыр алып китүләре турындагы мәгълүмат ирешеп, алар аны җәмәгатьчелек белән бүлешергә күпмедер өлгергән. Һәм шуның белән шул. Розуэлл инцидентына бүген дә нокта куелмаган. Америка хәрбиләренең яңа төр очу аппаратын сынагандагы уңышсызлыгы булганмы ул, әллә инде чит планета яисә параллель дөнья вәкилләренең тормышка ашып бетмәгән визитымы – версияләр җитәрлек булып та, шушы көнгәчә беркемнең, шул исәптән рәсми органнарның да ачык, төгәл һәм бар кешене ышандырырлык аңлатма биргәне юк. Бүтән шуңа охшаш күренешләрне анализлап, үз нәтиҗәләрен чыгаручы башкалар булган җәһәттә дә.

Китап киштәмдә инде хәтсез еллар Владимир Ажажаның «Уфологическая мистерия» дигән, өч китаптан торган үзенчәлекле хезмәте ята. Узган гасыр азагында Мәскәүдә оешкан Уфология институтының элекке директоры ул трилогиядә НЛО дигән күренешнең реальлеген исбатлый, «нишләп йөриләр?» дигән сорауга үзенчә җавап бирә һәм иң мөһиме – бик күп еллар буе безнең өстә акыл үсеше, технологик алгарыш ягыннан нык алга киткән билгесез затларның торганлыгын бәян итә. Профессорга ышанганда, без барыбыз да диярлек шул югары акыл ияләре алып барган тәҗрибәләрдә катнашучы куяннар ролендә. Без – микроскоп пыяласында. Карыйлар, тәҗрибәләр үткәрәләр, үрчетәләр һәм савалар. Имеш, алар безне Җир дип аталучы резервациягә китереп урнаштырганнар да, үз хаҗәтләрендә рәхәтләнеп файдаланалар. Саву дигәндә, әлбәттә, без аларга сөт тә, ит тә, йон да, йомырка да бирмибез. Ул аларга кирәк тә түгел. Ә нәрсә бирәбез?

Сорауга җавап эзләп, бал кортлары дип аталучы үзенчәлекле «җәмгыять»кә мөрәҗәгать итик. Табигать иңдергән тәртип буенча яшәүче шактый камил күренгән ул цивилизациядә рациональ хезмәт бүленеше, шактый уникаль үрчү системасы, табигатькә, һава шартларына ифрат та шәп җайлашканлык. Тик шулай да ниндидер аң, зиһенлелек турында сүз сөйләп булмый. Зиһен, акыл ягы аз-маз булса, алар безгә төп ризыклары – җәй буе тырышып җыйган балны бирерләр, үзләрен саудырырлар идеме? Юк, бер калак бал өчен йөз тапкыр килеп чагып китәрләр иде. Ә болай без шәпләп алар җитештергән балны ашыйбыз. Чөнки алар үзләрен кемнәрдер файдаланганны аңлар дәрәҗәдәге җан ияләре түгел. Бал кортыннан өстен торган, сугымга асралган мал, җигәр өчен тотылган ат та нәкъ шундый хәлдә. Ихтимал, без – кешеләр дә – иң югары аңга, технологияләргә ирешкән цивилизацияләр белән чагыштырганда өметсез томаналардыр. Безләрне ни рәвешле сауганнарына беркайчан да төшенә алмаячакбыз, ахрысы.

Кайбер уфологлар бездән мең тапкыр зиһенлеләргә кешенең психик, эмоциональ энергиясе кирәк, алар шуның белән туена, ди. Тик дәлилләп бирә алмый. Ажажа исә НЛО иярләгән затлар – гуманоидларның кешеләрне кыска вакытка даими урлап торуын (абдукция), һәркемнән дә диярлек биоматериал алуларын исбатларга алына. Имештер, бала чакта бөтен кеше дә абдукция аша үтә. Ул затларга аерым кешедәге генетик материал, һәрберебез өчен үзгә булган генетик код кирәк икән. Соңыннан, ген күрсәткечләре буенча, һәр ун кешенең берсе даими донорга әйләнә, хатын-кызлардан күкәй күзәнәк, ирләрдән орлык алына, ди галим. Безне савучылар, имеш, инде хәтсездән ген инженериясе өлкәсендә үзләре мөһим санаган эшләр алып баралар. Бәлки кеше затының үзләре теләгән төрен, «сөт»не күбрәк биргәнен булдырасылары киләдер. Ажажа да алар миссиясен, алар максатларын без ахыргача белә алмаячакбыз дигән фикердә. Ә инде «каян килгәннәр», дигәндә, профессор «тәлинкә» пилот һәм пассажирларын башка планета вәкилләре дияргә ашыкмый. Ничек кенә булмасын, Җиргә без түгел, алар хуҗа икән.

НЛО иярләгәннәрнең технологик мөмкинлекләре турында күпне фаразларга мөмкин булганда да, алар алгарышының мораль ягы турында нидер белдерергә хәтта Ажажа да батырчылык итми. Ул як бөтенләй караңгы кала. Ниндидер әхлакый нормалар, миһербанлылык, шәфкать, ярату – бу сыйфатларның барысын да коры прагматизм алыштырган булырга да бик мөмкин. Кешелек тә акрынлап шул якка бара кебек. Кешене өйрәнәләр, савалар икән, адәми зат аларга кирәк. «Алардагы техник мөмкинлекләр белән безне юкка чыгару – минутлык эш, тик алар аны эшләми», – ди галим.

БЕР КӨНДӘ – ИКЕ ШАТЛЫК

Корбан гаете якынлашкан көннәрдә Чувашиянең Урмай авылында тагын бер иман йорты сафка басты. Биредә төзекләндерүдән соң Җәмигъ мәчете ачылды. Бу көнне республикада «Тын чикләрне төзүчеләргә» мемориалы да пәйда булды. Тантаналы чараларда Чувашиягә эшлекле сәфәр белән килгән Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

tatarstan.ru

Бәйрәмгә – яңа мәчет

Урмай авылының күрке булып торган Җәмигъ мәчете 1990 елда төзелгән. 2014 елда мәхәллә вәкилләре аның мәйданын арттыру өчен иске бинаны төзекләндерергә карар кылган. Мәчет диварының аскы өлешен үзгәрешсез калдырганнар. Мәчет беренче имамы Рәхимулла хәзрәт Минһаҗетдинов исемен йөртә. Җәмигъ мәчетен ачу Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышланган.

Тантаналы чарада катнашкан Рөстәм Миңнеханов яңа мәчет ачылуның тагын бер әһәмиятле ягына игътибар итте.

– Татарстан һәм Чувашия Республикалары күршеләр генә түгел. Без – тугандаш халык вәкилләре. Безнең тамырларыбыз бер. Без җирле җитәкчелекнең башка халыклар һәм дин вәкилләренә игътибар бирүләрен күрәбез. Аларга үз диннәрен, милли гореф-гадәтләрен саклап калу өчен барлык шартлар да тудырылган. Чувашия Республикасы җитәкчелегенә татар халкының диненә һәм мәдәниятенә сак караулары өчен рәхмәт белдерәсем килә», – диде Татарстан Президенты.

Бу сүзләрнең хаклыгына инану өчен, рәсми саннарга күз салу да җитә. Чувашия Республикасы башлыгы Олег Николаев сүзләренә караганда, бүген биредә 128 милләт вәкиле дус-тату гомер итә. Татарлар халык саны буенча төбәктә өченче урында тора. «Татарлар республика тормышына зур өлеш кертә. Иң мөһиме – алар ата-бабаларыбыздан килгән гореф-гадәтләрне саклый. Сезгә чын күңелдән рәхмәт белдерәсем килә», – диде Олег Николаев.

Яңартылган мәчет белән танышканнан соң, ике республика җитәкчесе Урмай авылының актив халкы һәм мәчетне төзекләндерүгә өлеш керткән меценатлар белән дә очрашты. Урмай авылына сәфәре кысасында Рөстәм Миңнеханов моннан ун ел элек ачылган «Кара Пулат» мәчетендә дә булды. Мәчет Идел Буе Болгарындагы мәдәни объектларның архитектур үрнәге буенча төзелгән. Бүген ул рухи-мәгариф үзәк буларак та эшли.

Хәтер мәңгелек

Бу көннәрдә Чувашиядә хезмәт батырлыгы шәһәрләренең илкүләм форумы уза. Аның кысасында кичә республиканың Козлов районында «Тын чикләрне төзүчеләргә» мемориалы ачылды. Тантаналы чарада Россия Президентының иҗтимагый проектлар буенча идарә башлыгы Сергей Новиков, Россия Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле Игорь Комаров, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Россиядә тыл хезмәтчәннәре белән оборона сызыгы төзүчеләргә куелган беренче һәйкәл бу. Әлеге мемориал 38 металл стеладан торган һәйкәлдән һәм 4,5 метр биеклектәге таудан гыйбарәт. Бу стелаларның һәркайсы 10 чакрым озынлыктагы оборона корылмасын хәтерләтә. Мемориалның үзәгендә Мәңгелек ут белән район һәм шәһәрләр символлары гәүдәләнгән 26 гранит стела урнашкан.

Яңа мемориалга нигез ташы узган елның августында салынган. Бу һәйкәл тылда батырлык күрсәткән каһарманнарның, бигрәк тә хатын-кызлар һәм балаларның батырлыгын мәңгеләштерә. Россия Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле Игорь Комаров, әлеге вакыйганың әһәмиятен ассызыклап, Россия Президенты Владимир Путинның хатын укыды. «Илнең эре индустрия үзәкләре тирәсендә оборона сызыгы төзү сугыш тарихы битләрендә зур урын алып тора. Шуларның икесе – Казан һәм Сура каймалары Чувашия аша үткән. Халыкның шундый фидакарь батырлыгы истәлеге итеп бүген биредә «Тын чикләрне төзүчеләргә» мемориалы ачыла. Әлеге бөек монумент тарихи хәтерне сакларга, яшьләрдә ватанпәрвәрлек, ата-бабаларыбыз каһарманлыгы белән горурлык хисе тәрбияләргә ярдәм итәр дип өметләнәм», – диелгән иде ил башлыгы хатында.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та үз чыгышында иң беренче чиратта әнә шуңа игътибар итте. «Казан һәм Сура каймалары төзелү – безнең республикаларның хезмәт батырлыгы үрнәге. Сугыш елъязмасындагы татар һәм чуаш гаиләләрен берләштерә торган аерым бер вакыйга бу. Катлаулы һава шартларында кыска вакыт эчендә чик төзелгән. Без бу батырлыкны беркайчан да онытмабыз», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Чувашия Республикасы башлыгы Олег Николаев, үз чиратында, якын киләчәктә биредә яңа музей комплексы да пәйда булачагын искәртте. «Безнең өчен бүген бик әһәмиятле көн. Ел ярым вакыт эчендә без чуаш халкының Бөек Ватан сугышында күрсәткән хезмәт батырлыгын барлау өчен тарих битләрен өйрәнү юнәлешендә күпкырлы системалы эш алып бардык. Бу вакыт эчендә алты китап нәшер ителде, бик күп чаралар оештырылды. Мемориал ачылу – шушы мөһим чараларның берсе», – диде ул үз чыгышында.

ХЕЗМӘТТӘШЛЕККӘ – ЯШЕЛ УТ

Бүген Гродно шәһәрендә (Беларусь Республикасы) Беларусь һәм Россия регионнарының тугызынчы форумы узды, анда Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты. Форумның пленар утырышында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Минск өлкә депутатлар Советы арасында хезмәттәшлек турында килешү имзаланды.

Быел, гадәттәгечә, Россия Федерация Советы һәм Беларусь Республикасы Милли Җыены Советы тарафыннан оештырылган форум төбәкара хезмәттәшлек һәм Союз дәүләтенең берләшү процессларын тирәнәйтү темасына багышланган иде. «Форумның төп бурычларының берсе – киртәләрне алып ташлау һәм Россия белән Беларусь субъектлары арасындагы төбәкара мөнәсәбәтләрне алга таба үстерү өчен шартлар тудыру», – дип басым ясады Валентина Матвиенко, төбәк җитәкчеләре белән аралашканда. Федерация Советы Рәисе шулай ук Союз дәүләтенең бюджетын формалаштырганда һәм раслаганда конкрет төбәк проектларын гамәлгә ашыруга аерым игътибар бирергә, Россия белән Беларусьның төбәк хезмәттәшлеген киңәйтүгә «яшел ут» кабызырга тәкъдим итте.

«Татарстан Россия – Беларусь багланышларын үстерүгә үз өлешен кертә, – дип билгеләп үтте Фәрит Мөхәммәтшин, форумда журналистлар белән аралашканда, – 2004 елда Беларусь һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте арасында сәүдә-икътисади, фәнни-техник һәм мәдәни хезмәттәшлек турында килешү имзаланган иде һәм без Татарстан һәм Беларусь предприятиеләре продукциясен үзебезнең базарларга кертеп, товар әйләнешен арттыруга ирештек».

Соңгы ун ел дәвамында Беларусь республиканың төп тышкы сәүдә партнерлары бишлегенә керә. Әйтик, узган ел ике арада товар әйләнеше 850 млн доллар тәшкил иткән.

Фәрит Мөхәммәтшин Татарстан җитештерүчеләренең Беларусьта чыгарылган авыл хуҗалыгы техникасын яхшы бәяләүләрен һәм аларны предприятиеләрдә бик теләп кулланууларын искәртте. Хәзерге вакытта республика агросәнәгать комплексы технопаркының шактый өлешен Беларусь авыл хуҗалыгы машиналары тәшкил итә. «Ел саен Татарстанда үткәрелә торган Кыр көннәре Беларусь делегациясеннән башка узмый, – диде парламент башлыгы, – безнең коллегалар күргәзмә продукциясенең зур ассортименты белән киләләр, һәм ул ел саен яңартыла».

Хәзерге вакытта Алабугада ун ел элек нигез салынган «МТЗ-Татарстан» Минск трактор заводы предприятиесе базасында белорус машина төзелеше предприятиеләренең бердәм сервис-сату үзәге оештырыла, анда «МТЗ», «МАЗ», «Белавтомаз», «Гомсельмаш», «Бобруйскагромаш» һәм «Амкодор-агро» продукцияләре тәкъдим ителәчәк. Биредә шулай ук запас частьларның үзәк склады булачак һәм «Беларус» тракторларын җыю производствосын үстерү каралган.

Беларусь һәм Россия төбәкләренең тугызынчы форумының пленар утырышында шулай ук Минск өлкә депутатлар Советы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы арасында хезмәттәшлек турында Килешүгә кул куелды. Документны дәүләт хакимиятенең һәр ике якның закон чыгару органы җитәкчеләре Фәрит Мөхәммәтшин һәм Наталья Якубицкая имзалады.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республикада газ-мотор ягулыгы базарын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Газпром газ-мотор ягулыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының икътисад һәм социаль өлкә тармакларын үстерү бүлеге башлыгы урынбасары **Гафурова** Айсылу Марат кызына; Татарстан Республикасы Буа суд районы буенча 1 номерлы участогы җәмәгать судьясы **Төхвәтуллин** Ренат Абдрахман улына; Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының икътисади куркынычсызлык һәм коррупциягә каршы көрәшү идарәсе документаль тикшеренүләр бүлеге башлыгы урынбасары, полиция подполковнигы **Урматов** Камил Мәхмүт улына; Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Алабуга районы һәм Алабуга шәһәре территориаль бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары **Усманова** Фәния Габделхәй кызына; «Авиатөзелеш районының торак-коммуналь хуҗалык идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Гайфетдинов** Рөстәм Әнәс улына; «Евростройхолдинг+» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең кадрлар бүлеге башлыгы **Мөхетдинова** Эльвира Ренат кызына; «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры **Низамов** Рәшит Корбангали улына; «Россия инновация ягулык-энергетика компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Нургалиев** Ренат Гали улына; «Татарстан Республикасының мари милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе **Третьяков** Олег Александровичка; хезмәт ветераны **Шакирова** Фәридә Гариф кызына; Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең механикалаштыру буенча консультанты **Әхтәмов** Зөфәр Фатыйх улына; Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе дәүләт ветеринария күзәтчелеге бүлеге башлыгы **Гатин** Идрис Мөдәрис улына; Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы **Гатин** Мирзаһит Закир улына; «Кыят» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры (Татарстан Республикасының Буа районы) **Грачев** Владимир Александровичка; «Татмелиорация» траст компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары – баш инженеры **Зарипов** Альберт Шәүкәт улына; «Татарстан Республикасы буенча Җирләрне сугару һәм авыл хуҗалыгын су белән тәэмин итү идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе директоры **Хисмәтуллин** Марс Мансур улына; Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте үзәкләштерелгән дини оешмасының Чистай шәһәре һәм Чистай районы мөхтәсибәте җирле мөселман дини оешмасы имам-мөхтәсибе **Киямов** Марсель Солтан улына; Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Сәгъдиев** Рифкать Габбас улына; «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» филиалы сантехника участогы слесарь-сантехнигы **Сөләйманов** Рөстәм Рәүф улына **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

* * *

Республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен нефть сәнәгате ветераннары: **Дерябина** Валентина Васильевна; **Хафазетдинов** Шамил Нух улы **«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале** белән бүләкләнде.

Әти-әни кушканга түгел

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Чит илләрдә мәктәпне тәмамлагач, балаларга уйланырга вакыт бирәләр. Безнең яшьләргә мондый тәнәфес кирәкме? – дип мөрәҗәгать итте Ләйлә Фазлыева, залда утырган белгечләргә.

– Баланың тәнәфес алуы начар түгел. Әмма ул вакытны зая уздырмаска тиеш. Бу арада үсмер «Работа в России» платформасы аша үзенә эш таба ала. Киләчәге өчен кирәк булмаган һөнәр сайласа да, аптырарга кирәкми. Теләсә кайсы тәҗрибә файдага булачак, – диде Софья Тонконог, үз фикерен белдереп.

Яшьләр арасында уздырган сораштырулардан күренгәнчә, кайберләренең вузга бөтенләй укырга керәсе килми, алар эшкә урнашуны кулайрак күрә. Бу яшьләрнең тизрәк акча эшләү теләгенә дә бәйле. Шуңа күрә ул-кызыгыз эшкә урнашырга тели икән, аның теләген хупларга, быел керә алмасаң, икенче елга да вакыт бар, дип тынычландырырга кирәк.

Вузларга җыенган яшьләрне барыннан бигрәк БДИ баллары җитмәү, уку йортында рейтингларның үзгәреп торуы куркыта. Бу очракта баланы ничек тынычландырырга? Кызы имтиханнарны уңышлы тапшырган әни буларак, Казан инновация университеты ректоры Асия Тимирясованың да фикерен сорадылар.

Ректор башта Бөтенроссия халык җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге уздырган сораштыру нәтиҗәләрен китерде. Монда шактый кызыклы вазгыять күзәтелүен әйтте. Яшьләр һөнәрне әти-әни фикеренә азрак колак салып, үз теләкләре буенча сайлый башлаган.

– Баланы бирәү дә әти-әнисеннән дә яхшырак белми. Шуңа күрә без аларга үз киңәшебезне бирергә тиеш, әмма фикеребезне мәҗбүри тагарга ярамый. Бала арып китә икән, ял итсен. Паркка, кино, театрга барып, бераз онытылып кайтсын, – диде ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Укырга кергәндә, әти-әниләр балаларына психологик яктан ничек ярдәм итә ала?

– Үзләрен тыныч тоткан әти-әни генә баласына булыша ала. Әгәр сез бик нык борчыласыз икән, башта үзегез тынычланыгыз. Балаларга яратуыгызны гел әйтеп торыгыз. Ял итү, йокы да мөһим. «Укырга керә алмасаң, нишлибез?» дигән сорауга бергәләп җавап табарга тырышыгыз. Стрессны җиңү өчен сулыш алу күнегүләренең, рәсем ясауның файдасы зур, – диде «Росток» психология-педагогика үзәге психологы Инна Идрисова.

Сәрия МИФТАХОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 15 июнендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2000 елның 3 мартындагы 95 номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 3 (3); 2003, № 8; 2008, № 11 (III өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш), «Дәүләт Советының сайланган депутатлары саныннан» сүзләрен «Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән саныннан» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2 статья

«Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2011 елның 1 августындагы 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 8; 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 1 өлешендә «Дәүләт Советының сайланган депутатлары саныннан» сүзләрен «Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән саныннан» сүзләренә алмаштырырга;

2) 10 статьяның 2 өлешендә «Дәүләт Советының сайланган депутатлары саныннан» сүзләрен «Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән саныннан» сүзләренә алмаштырырга.

3 статья

«Татарстан Республикасында парламент контроле турында» 2016 елның 12 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 10 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 1 – 2), «Дәүләт Советының сайланган депутатлары саныннан» сүзләрен «Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән саныннан» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

4 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 27 июнь, № 38-ТРЗ

Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 15 июнендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

44^6 статьяда:

а) 6 пунктта «субвенцияләрне исәпләп чыгару» сүзләрен «субвенцияләрнең күләмен билгеләү» сүзләренә алмаштырырга;

б) 6^1 пунктта «субвенцияләрне исәпләп чыгару» сүзләрен «субвенцияләрнең күләмен билгеләү» сүзләренә алмаштырырга;

2) 55^2 статьяда түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

«7. Татарстан Республикасы Юллар фонды бюджет ассигнованиеләре, региональ яисә муниципальара әһәмиятле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү (реконструкцияләү), капиталь ремонтлау һәм ремонтлау һәм (яисә) юлларны төзү (реконструкцияләү), капиталь ремонтлау һәм ремонтлау эшләре башкарылган очракта, юлның транспорт чарасы йөрү өлеше белән бер тигезлектәге трамвай юлларын (контакт челтәрләреннән һәм югары көчәнешле подстанцияләрдән тыш) реконструкцияләүгә, капиталь ремонтлауга һәм ремонтлауга, шулай ук, җирле әһәмиятле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү (реконструкцияләү), капиталь ремонтлау һәм ремонтлау һәм (яисә) юлларны төзү (реконструкцияләү), капиталь ремонтлау һәм ремонтлау эшләре башкарылган очракта, юлның транспорт чарасы йөрү өлеше белән бер тигезлектәге трамвай юлларын (контакт челтәрләреннән һәм югары көчәнешле подстанцияләрдән тыш) реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм ремонтлау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга субсидияләр рәвешендәге бюджетара трансфертлар бирүгә җибәрелергә мөмкин.»;

3) 9^2 кушымтада:

а) исемендә «субвенцияләрне исәпләү» сүзләрен «субвенцияләрнең күләмен билгеләү» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктта «финанс чыгымнары нормативын» сүзләрен «чыгымнар нормативын» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Чираттагы финанс елына һәм план чорына субвенция күләмен билгеләгәндә муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының мәгариф өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары тарафыннан чираттагы финанс елына һәм план чорына субвенциянең күләме билгеләнә торган елның 1 сентябренә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында белем алучыларның уку-укыту программаларының төрләре, юнәлеше (профильләре), гомуми белем бирү дәрәҗәләре, белем бирү рәвешләре буенча планлаштырыла торган саны (алга таба – белем алучыларның план саны) кулланыла.»;

г) 5 пунктта:

беренче абзацта «субвенцияне (S_i) исәпләп чыгару» сүзләрен «субвенциянең (S_i) күләмен билгеләү» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$S_i = S_N + S_{SN} + S_K + S_u$,»;

дүртенче абзацта «санына карап» сүзләрен «план санына карап» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «санына карап» сүзләрен «план санына карап» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«S_u – i-муниципаль берәмлегенә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен дәреслекләр сатып алуга чыгымнар өлешендә тәэмин итүгә субвенция күләме.»;

д) 6 пунктта:

беренче абзацта «санына карап» сүзләрен «план санына карап» сүзләренә, «исәпләп чыгару» сүзләрен «билгеләү» сүзенә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «финанс чыгымнары нормативлары» сүзләрен «чыгымнар нормативы» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «белем алучылар санын исәпкә алып» сүзләрен «белем алучыларның план санын исәпкә алып» сүзләренә, «факттагы» сүзен «план» сүзенә алмаштырырга;

е) 7 пунктта:

беренче абзацта «сыйныфлар санына карата» сүзләрен «сыйныфлар буенча белем алучыларның план санына карап» сүзләренә, «исәпләп чыгару» сүзләрен «билгеләү» сүзенә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «финанс чыгымнары нормативлары» сүзләрен «чыгымнар нормативы» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «факттагы» сүзен «план» сүзенә алмаштырырга;

ж) 7^1 пунктта:

беренче абзацта «субвенция күләмен исәпләп чыгару» сүзләрен «субвенциянең күләмен билгеләү» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Q – i-муниципаль берәмлегендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы тарафыннан башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүче уку-укыту программаларын, шул исәптән җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын, гамәлгә ашыручы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләү ала торган педагогика хезмәткәрләренең фаразлана торган саны;»;

з) түбәндәге эчтәлекле 7^2 пункт өстәргә:

«7^2. I-муниципаль берәмлегенә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен дәреслекләр сатып алуга чыгымнар өлешендә тәэмин итүгә субвенция күләмен билгеләү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$S_u = \sum_{n=1}^{3} (H_{ij} \times R^u)_n ,$$

монда:

H_{ij} – i-муниципаль берәмлеге территориясендә j-муниципаль гомуми белем бирү оешмасының төп гомуми белем бирү программалары (башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары) буенча сыйныфларда белем алучыларның план саны;

R^u – дәреслекләр белән тәэмин итүгә чыгымнар нормативы;

n – гомуми белем бирү дәрәҗәсе.»;

и) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә, шул исәптән дәреслекләр белән тәэмин итүгә, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итүгә чыгымнар нормативы чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына субвенция күләмен билгеләгәндә кулланыла.»;

к) 9 пунктта «дәүләт гарантияләрен» сүзләреннән соң «, шул исәптән дәреслекләр белән,» сүзләрен өстәргә, «финанс чыгымнары нормативларын» сүзләрен «чыгымнар нормативларын» сүзләренә алмаштырырга;

4) $9^{2.1}$ кушымтада:

а) исемендә «субвенцияләрне исәпләү» сүзләрен «субвенцияләрнең күләмен билгеләү» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктта «финанс чыгымнарының» сүзләрен «чыгымнарның елына» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Чираттагы финанс елына һәм план чорына субвенция күләмен билгеләгәндә муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының мәгариф өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары тарафыннан чираттагы финанс елына һәм план чорына субвенциянең күләме билгеләнә торган елның 1 сентябренә муниципаль мәгариф оешмаларында төркемнәрнең иң чик тулылыгыннан артмаган тәрбияләнүчеләрнең категорияләре, яшь составы буенча планлаштырыла торган саны кулланыла.»;

г) 5 пунктның дүртенче абзацында «финанс чыгымнарының» сүзләрен «чыгымнарның» сүзенә алмаштырырга;

д) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә чыгымнар нормативы чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына субвенция күләмен билгеләгәндә кулланыла.»;

е) 7 пунктта «финанс чыгымнары нормативларын» сүзләрен «чыгымнар нормативларын» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 41 статьясындагы унынчы абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2019 елның 19 февралендәге 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 19 (I өлеш), № 60 (I өлеш), «2023 елның 1 гыйнварына» сүзләрен «2026 елның 1 гыйнварына» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3 статья

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 2021 елның 27 декабрендәге 101-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), аңа «32^1 статьясындагы 3 пунктының,» сүзләреннән соң «43 статьясындагы бишенче абзацының (федераль законнарда билгеләнгән очраклар өлешендә),» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

4 статья

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44^6 статьясы (әлеге Закон редакциясендә), Татарстан Республикасы Бюджет кодексына 9^2 һәм $9^{2.1}$ кушымталары (әлеге Закон редакциясендә) нигезләмәләре Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына бюджетлардан башлап кулланыла.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 27 июнь, № 39-ТРЗ

«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 15 июнендә кабул ителде

1 статья

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа унҗиденче абзац өстәргә:

«янгын чыгу турындагы сигналларны «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль законның 83 статьясындагы 7 өлеше нигезендә янгыннан саклану бүлекчәләренә дә кабатлауны оештыру тәртибен раслау;»;

б) унҗиденче абзацны унсигезенче абзац дип санарга;

2) 15 статьяның беренче өлешендә «оешмаларда» сүзеннән соң «(куркыныч җитештерү объектлары эксплуатацияләнә торган Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган стратегик предприятиеләр һәм стратегик акционер җәмгыятьләр исемлегенә кертелгән дәүләт корпорацияләреннән һәм оешмаларыннан һәм аларга ведомство буйсынуындагы объектлардан тыш)» сүзләрен өстәргә.

2 статья

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 2 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 27 июнь, № 40-ТРЗ

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 15 июнендә кабул ителде

1 статья

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.6 статьяның 1 өлешендә «2.8,» саннарын төшереп калдырырга, «3.2 – 3.7» саннарын «3.2 – 3.6» саннарына алмаштырырга;

2) 2.8 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 3.7 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

4) 7.1 статьяда «3.7 – 3.10» саннарын «3.8, 3.10» саннарына алмаштырырга;

5) 7.2 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

6) 8.1 статьяда:

а) 1 өлештә «7.2,» саннарын төшереп калдырырга;

б) 13^1 өлештә «3.7,» саннарын төшереп калдырырга;

в) 14 өлештә «2.6 – 2.8» саннарын «2.6, 2.7» саннарына алмаштырырга, «3.7,» саннарын төшереп калдырырга.

2 статья

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 10; 2014, № 7; 2015, № 3, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш) «2.4 – 2.8» саннарын «2.4 – 2.7» саннарына алмаштырырга.

3 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 27 июнь, № 41-ТРЗ

Поэма

КИТӘ КАЗЛАР ДОНБАССКА

Ренат ХАРИС

Ренат Харис архивыннан

Төгәл ярты гасыр элек, 1972 елның 23–29 май көннәрендә Украинаның Ворошиловград өлкәсендә (хәзер Луганск Халык Республикасы) Татарстан әдәбияты һәм сәнгате көннәре узды. Анда күренекле язучылар, Опера һәм балет театры, филармония артистлары, журналистлар катнашты.
Рәсемдә: Татарстан делегациясен Ворошиловград (хәзер Луганск) аэропортында каршылау. Анда Ренат Харисны, Назнинә Сабитовскаяны, Венера Шәрипованы, Вафирә Гыйззәтуллинаны (чүгәләгән), Габдрахман Минскийны, Зәки Нурины, Шамил Рәкыйповны, Айрат Арслановны, Эмиль Җәлаләтдиновны, Наҗия Теркулованы танып була. Кайбер артистлар һәм язучылар фотога керми калганнар.

1.

Радиодан җыр яңгырый:
«…Китә казлар Донбасска,
мин дә уйлап торам әле
шул казлардан калмаска…»
Телевизор, радиода
кич, иртә, төнлә, көндез

Җанның тынычлыгын ала
«Донбасс» дигән кырыс сүз
йә шартлау булып яңгырап,
йә өмет булып балкып,
йә Рейхстагка эленгән
ал әләм кебек калкып…

Күз алдыма килеп баса
ташкүмер эскертләре,
конус-конус терриконнар –
мәһабәт, искитмәле!..
Бүген Донбасс якларында
планетар эшләр бара:

Яшәеш тәртибенә Җир
яңа, гадел юл яра
Ватаным куәте белән,
аның йөрәге белән,
Алып батырдай сугышып,
фашист өрәге белән…

2.

Искә төшә Нәби Дәүли
«Донбасс» сүзен ишетсәм,
Күрәсең, «Донбасс»
сүзендә
шагыйрьнең рухы исән!..

«Китә казлар,
китә казлар,
китә казлар Донбасска!

Мин дә уйлап торам әле
шул казлардан
калмаска», –
диеп җырлап җибәрәбез,
бик моңлы көйгә салып,
нинди җыр чыгарган диеп,
сокланып, даһи халык!..
«Әй халык ул…
ни дип әйтим –

даһи түгел пычак та…
Ул җырны бит
мин чыгардым,
чыгардым даһи чакта –
алтынчымы, җиденчеме
сыйныфта укыганда,
йөрәктәге шагыйрьлекне
мәхәббәт тукыганда», –
дигән иде Нәби ага

утырганда чәй-мәйләп,
язмышы юллары очын
данлы Донбасска бәйләп…

Ул чыгарганмы,
башкамы?..
Ә нигә ышанмаска?!.
Китә казлар… Казлар гына
китсә икән Донбасска…

3.

Царицында (аның әле
Сталинград түгел чагы)
детдом малае Нәбидә
кабына җыр чырагы.
Нәбиуллага да Дәүли
булырга әле ерак –
ул әлегә шук такмаклар
гына чыгарып тора…
Белми әле эчәчәген
сугыш бәла-казасын,
белми әле «Җимерелгән
бастион»ны язасын…

Илнең әле күмер ягып,
җан җылыткан еллары,
Донбасска таба юнәлгән
аның барлык юллары.
«Акчаны көрәп алалар,
имеш, шахтага төшеп…»
диеп уйлап, шул якларга
ашыккан бик күп кеше…

Укытучы Разыяның
егетен дә беркөнне
шул якларга алып киткән

киек казлар төркеме…
Галиулласын Разыя
бик сагынган, елаган,
Нәбиулладан бер шигырь
чыгаруын сораган.
Әллә киек казлар киткән,
әллә кайткан чак булган.
Ул язып биргән дүрт юлда
шул вакытлар чагылган…
Ә Разыяның тавышы
моңлы һәм җылы икән,
ул Нәби язган сүзләрне

җырлый да елый икән:
«Китә казлар, китә казлар,
китә казлар Донбасска!
Мин дә уйлап торам әле
шул казлардан
калмаска…»

Разыя да китеп барган
сагынуын тыялмый…
Китеп барган,
ымсындырып,
Нәбиулла хыялын…

4.

Нәбиулла хыялы да
тиздән канат кагына –
җәй җиткәч, ул да кузгала
киткән казлар ягына.
Донецк заводында егет

тимерчелектә эшли…
Тирә-юньнән сораштырып,
Разыяларны эзли…
Һәм таба Кадиевкада,
Луганск өлкәсендә!

Андагы шахталар даны
татарлар җилкәсендә…
Галиулла, күмер чабып,
уңышларга ирешкән,
ә Разыя бала көтә,

әлегә йөрми эшкә…
Донбасс Нәби Дәүли өчен
сагынычлы җир икән…
Юк-юк, алай гына түгел,
языласы җыр икән!..

5.

…җитмеш икенче ел мае…
Ворошиловградка
бәйрәмгә килдек, халыклар
дуслыгын аклап-хаклап.
Безнең «сәлам»ны кочаклый
аларның «привет»ы.
Һәрберебезнең кулында –

кунакчыллык букеты.
Язучылар һәм артистлар
алардан да, бездән дә…
Биибез ат дулагандай,
йаки казлар йөзгәндәй.
Арада Нәби Дәүли дә
бии селкеп чал ялын,

авызы колак артында,
күзләрендә чаялык…
Алтмышын узган шагыйрем
сабый кебек шатлана.
Сак басыгыз, ди, Донбасска –
ишелмәсен шахталар!
Ул уена да кертмәгән

фәлән елдан соң монда
биисен миналар һәм
свастикалы бомбаның,
неонацист үз иленнән
үзе үч алачагын…
Ә бүген Нәби агада
уянган егет чагы…

6.

Донбасс минем күңелгә дә
ят түгел, якты ызан –
әтием, связист булып,
моннан сугышып узган.
Лисичанск, Кадиевка
ул сөйләгәннәр аша
хәтеремнең һәрчак ачык
ишегенә тоташкан…
Шахталарда без татарча
шигырь сөйләп йөрибез.
Шахтёрларның алкышында
балавыздай эрибез,
әйтерсең алар учына
ташкүмер кузы күчкән!
Ана телен саклаганнар,
дип куанабыз эчтән.
Ә казыны «махан» диләр…
шул бераз сәерсетә…
Горилкаларын татыгач,
сәерсенүләр бетә…

Шигырьгә медальләр чыңы
кушылган бер кичәдә
Нәби Дәүли сорау бирде
алдан сөйләшмичә дә:
– Галиулла һәм Разыя
дигән гаиләне сез
белмисезме? Менә шуны
ачыкларга телибез…
Бер карт шахтёр
торып басты:
– Аларны кем белмәгән:
икесен дә алып китте
фашист мәлгунь элмәге –
еврей инженерын алар
яшереп саклаганнар,
һәм коммунист
шахтёрларны
дошманга сатмаганнар.
Галиулла шахталарны
эшләмәскә котырткан,

ә Разыя бер фашистның
яңагына утырткан,
битләрен тырнап
бетергән –
үзенчә алган үчен,
пешкән җиләктәй кызына,
нәләт, кул сузган өчен…

Кич, Кадиевкадан кайткач,
елады Нәби ага,
кабак зурлык
йодрык белән
өстәлгә кага-кага,
борын канатларын җәеп,
сулкылдатып сулышын,
итләч иреннәрен кысып,
каргый-каргый сугышны…
Һәм ачты гомерлек серен
беркатлы бала сыман –
гашыйк булып йөргән икән

Разыя апасына!..
Галиулладан көнләшеп,
җаны әйләнгән көлгә,
«Ник дуэльләр юк икән?!»
– дип,
уфтанган чын күңелдән…

Мин шул чактагы
Дәүлидән
егерме яшькә картрак…
Аны искә алган саен
күз кабакларым тарта,
әллә Донбасс хәбәрләре
тетрәндерә нервымны…
Әлбәттә, тик хәерлегә
генә юрыйм мин моны,
белгән догаларым укыйм
теләкләр тели-тели,
чөнки җанга якын якта
сугыш дәһшәте гүли…

7.

Донбасс, Донбасс!
Син күңелгә
ник кадерле шул тикле?!
Дәү әниемнең туганы
шагыйрь Максуд Сөндекле
синдә исем алгангамы?!
Йә сөенә-сөенә
һәр аштa җырлагангамы
моңлы «Шахта» көенә?!
Нәби Дәүлинең елавы,
«Мин яздым…» дигән сүзе
хәтердә терелгәнгәме
үзәкне өзеп-өзеп;
әллә солдат әтиемнең
кирза итек эзләрен
шигырь итеп күргәнгәме
минем күңел күзләрем?!

Синдә Һади Такташ йөргән,
булган Шәйхи Маннур да.
Алардан калган кайтаваз
торгангамы яңгырап,
әллә шахта асларында
татар күп калгангамы?!
Әй, Донбасс, сине мин,
никтер,
җаныма ялгаганмын!
Сиңа төшкән ракеталар
яралыйлар мине дә,
минем дә өем ватыла
сиңа тигән минадан.
«Байрактар»лар,
«Джавелин»нар
шартлыйлар ич эземдә,
төтен тулып ялкынсыта

минем калкан биземне.
Мин дә фашист
тарафыннан
тере калкан ителәм…
Менә шулар, кузы булып,
тия йөрәк итемә…
Минем язу өстәлемнән
күтәрелгән ракета
сиңа ташланган ерткычның
тетмәсен шәпләп тетә…
Гитлерчыга булган нәфрәт
көчәйтә бүгенгесен…
Йөрәктә тантана итә
булачак җиңү хисе!

Сине, Донбасс, беркемгә дә
бирмәм – шул минем нәзер:

мин шахтаңда
«Сармат» булып
сакта торырга әзер.
Әзер беспилотник булып
очарга Җир тирәли –
күңел күзем белән Җирдә
бик күп хәтәр күрәмен…
Ләкин кемгә җиткерергә?
Кем безне саклый ала?
Мин уйланам…
Башым чатный…
Сорау җавапсыз кала…
Мин ышанам:
барлык сорау
тиешле җавап табар –
бүгенге бөтен авырлык
алларыңда юл сабар!..

8.

Кайта казлар, кайта казлар,
кайта казлар Донбасстан…
Быел безгә кайтып төшкән
казлар күзен кан баскан.
Кайта казлар, кайта казлар,
кайта безнең күлләргә…

Нинди хәбәр алып кайта?
Алып кайта кемнәргә?
Латин* V хәрефе булып
кайталар тезелешеп…
Бу хәрефне тик яхшыга
юрый хәзер бар кеше…

Нәби аганың үрнәге
җанымны тора үртәп –
«Шахта» җырына үземчә
мин дә үзгәреш кертәм,
ике сүзгә һәм бер юлга,
һәрбер хәрефен үбеп,

һәм эчемнән генә җырлыйм
дога укыган кебек:
Кайта казлар, кайта казлар,
кайта казлар Донбасстан…
Ходай бирсен һәр солдатка
шул казлардан калмаска!

30 май – 13 июнь, 2022. «Аккош күле» – Казан

*V – (Victory) – җиңү символы.

ХА-ХА-ХАНӘ

Шушы урында көләсе

МӨСЛИМ КЫЗЫКЛАРЫ

Һәр төбәк үзләренә генә хас мәзәкләргә, тапкыр сүзгә бик бай. Җор теллелеге белән авырлыкларны да баса, тормышны кызыклы, мәгънәле итә. Әйдәгез, мәзәкләр, тапкырлык капчыгын бергәләп барлыйк һәм аны газета укучыларыбыз хөкеменә дә тәкъдим итик әле. Сездән мәзәкләр, кызык-мызыклар көтәбез.

Муслюмовский атаман – Роман

Социализм еллары. Бөгелмәдә шоферлыкка укучы бер төркем Мөслим егетләре Сабантуй карарга чыккан. Матур гына ял итеп, хисләнеп утыра болар. Карасалар, шикле бер төркем боларга таба килә. Шунда Сабитов Рифкать әйтеп куя:

– Егетләр, болай итәбез, мин атаман булам, ә сез миңа хезмәт күрсәткән булып кыланырсыз, тегеләр белән үзем сөйләшермен.

Тегеләр килүгә, егетләрнең берсе агач яфраклары белән чебен куып, икенчесе тастымал белән җилләтеп, өченчесе ашарга китереп йөргән булып кылана. Табын уртасында кукраеп утырган Рифкатьтән тегеләр сорап куя:

– Кто такой?

– Муслюмовский атаман – Роман, – ди Рифкать.

– Болар да безнеңише «шантрапа» икән, – дип китеп бара Бөгелмә егетләре.

«Сельхозтехника»да шофёр булып эшләгән чорда да машинасы һәрвакыт төзек булды, шундый тапкырлыгы, үткенлеге өчен Рифкать абыйны хөрмәт иттеләр.

Файрус Гусман!

Ельцин бабай тәки сүзендә торды: өч ел эчендә барыбызны да «миллионерлар»га әйләндерде дә куйды. Хезмәт хакын да 6–10 миллион сум ала башладык, тик шунысы гына начар: кибеттә бу акчага алырлык әйбер юк, бер кап шырпы да 1000 тәңкә тора. Гөрләп эшләп торган завод-фабрикалар туктап калды, колхоз-совхозлар бөлгенлеккә төште. Укытучылар, врачлар, инженерлар, завод эшчеләре тамак ялына базарга чүпрәк-чапрак сатарга чыгып басты. Товар алмашу, бартер системасы хутка китте, бандитлар, жуликлар, коммерсантлар күпләп үрчи башлады. Шул чорда Авыл хуҗалыгы идарәсенең механизация бүлегенә Пензадан шалтыраталар:

– Я отправил вам счет на оплату механизмов и запчастей.

– С кем имею честь? – мин әйтәм.

– Абрам Моисеевич Гроссман, – ди бу.

– Я просмотрел ваши счета – запчасти слишком дорогие, мы не возьмём, – дим.

– А кто вы такой? – ди бу.

Мин моны кызык итәргә булдым, яһүдчәләп:

– Файрус Гусман! – дип җавап бирдем. Телефонның теге башында бер минутлык тынлык урнашты. Монда да яһүдләр бар икән, дип уйлагандыр, күрәсең. Бераздан:

– Я согласен с вами, на все запчасти цены снижаю на 15%, – ди бу.

– Вот это другой разговор, отправьте новые счета на оплату, – дип трубканы куйдым.

Яһүд белән яһүд уртак тел тапмыймы соң инде!..

«Только Кир-кир не надо»

80 нче еллар башында районга Әрмәнстаннан күпләп төзүчеләр килә башлады. Безнең җитәкчеләр аларны бик хуплап каршы алып, эшкә урнаштырып, хезмәт хакын да мулдан түләп бардылар. Шул чорда әрмән бригадиры «Сельхозтехника»га йөк машинасы сорап килә. Моңа Кыр-кыр кушаматлы Расил йөрткән «Урал» машинасын бирәләр.

Әрмәннәргә хезмәт хакы мул түләнгәнен искә алып, Расил алдан ук шарт куйган:

– Ашату-эчерү – сездән, ә эштән соңга калып, йөк бушаткан өчен 50 сум акчалата түләрсез.

Чаллыда йөкне төягәч, әбәт ашарга ашханәгә кергәннәр. Расилның тамагы ачкан, берүзенә ике кешелек ашарга алып, чын күңелдән сыйланып чыга.

Кайткач, цементны складка бушатырга булалар. Эш төгәлләнер вакыт җиткәч, Расил тиз генә машинасын артка чигереп, склад капкасын бикләгән дә:

– Давай оплату за сверхурочные работы – 50 рублей, – дип ультиматум куйган.

Нишләсеннәр инде, төн буе салкын складта ятканчы дип, әрмәннәр 50 сумны түләгән.

Икенче көнне йөкнең калган өлешен алып кайтырга тагын Расилны куйганнар. Моны ишеткән әрмән бригадиры директорга кереп:

– Ой-ой, Заки Исламович, дорогой, ради бога, дайте другого, только Кир-кир не надо, очень много кушает, – дигән.

Фәйрүс ГОСМАН.
Мөслим

«Бүтән алай итмәм, Гөлнара!»

Илфак ХАФИЗОВ

Ташлама

Шундый рәхәт заманда яшибез. Нәрсә кирәк – бар да бар! Элеккеге вакыттагы кебек һәр кибеткә, яки базарга кереп йөрисе юк. Интернетны гына ачасы. Бөтен мәгълүмат шунда. Телисең икән – барып аласың, телисең икән – өеңә китерәләр. Тик безнең татар тотып карамый ышанмый бит.

Бер көнне кич белән Казан шәһәрендә булды бу хәл. Яраткан хатыным телефонга сылтама җибәргән. Ачтым, каш сыза торган көрән каләмгә 15 процентлы ташлама. Ярар, мин әйтәм, югалтмаска җибәреп куйгандыр. Ә, юк икән… Мин аны-моны аңлаганчы, гадәттә сәгатьләр буе җыена торган тормыш чәчәгем киенеп-ясанып, ишек төбендә тора.

– Кая киттең? – мин әйтәм.

– Ничек инде кая? Күрмәдеңмени? – дип аптырады җаным. Күңелем куырылып куйды. – Минем каләмгә 15 процент ташлама бирәләр. Тизрәк җитешергә кирәк…

Әти миңа: «Озак яшисең килсә, хатын-кыз белән бәхәсләшмә, барыбер үзенекен итә», – дигән иде. Җыенып чыгып утырдык машинага. Каләм шәһәр уртасындагы кибеттә икән. «Яндекс-навигатор» кып-кызыл, 10 баллык «бөке» күрсәтә. Ярар, мин әйтәм, телне тешләп, этинең сүзләрен истән чыгармый:

– Барып кайтыйк.

Бер сәгать үтте дигәндә, ниһаять, барып җиттек сәүдә үзәгенә.

– Бар, тиз генә кереп чык, мин сине машинада көтеп торам, – дидем аппагыма. Шул чак алсуланып, балкып торган йөзе ачы лимон капкан төсле җыерылды бәгыремнең. Күз карашларыннан йөрәгем куырылып алды.

Үзегез дә аңлагансыздыр, бергәләп кердек кибеткә. Мөлаем генә каршы алдылар, ни кирәген сорадылар да билгеле бер бүлеккә алып килделәр. Ничек шулай мизгел эчендә үзгәреп була икән ул? Сөеклемнең «лимон капкан» битеннән җилләр искән. Май ялаган мачы баласы төсле канәгать. Йөрәк тибешем бераз тигезләште. Тик бу әле вакытлыча гына тынычлык булган икән. Күркәм ханым алдыбызга көрән төстәге 9–10 каләм тезде. Күземне кат-кат уып карадым. Аңлыйсызмы, 9–10 бер үк озынлыктагы көрән төстәге каләмнәр!.. Ә тормыш чәчәгем шулар арасыннан сайлап маташа. «Нәрсәсен сайлап торасың? Көрән – көрән инде ул. Берсен ал да киттек», – дигән идем… Кылт итеп этинең искә төште. Дөресрәге, төшерделәр…

Хатын-кыз дуслыгы юк дигән булалар. Булмас ди, бар! Аягын авырттырган куян баласына ташланган бүре көтүе кебек кибеттә эшләүче ике ханым миңа көрән төсләрнең аермасын аңлата башлады. Ә арттарак «мине оялудан кызарырга мәҗбүр итәсең» дигәндәй караш белән бердәнберем тора.

Гомердә онытылмаслык иттеләр. Ник килгәнемә генә түгел, ник туганыма үкенә башладым. Нинди ташлама, мин өстәп тә түләргә әзер. Тизрәк бирегез генә шул каләмне… Тик юк, кармакка эләктең исә, җайлы гына ычкынырмын дип өметләнмә. Кыздыралар рәхәтләнеп. Кызлар аңлатып бетергәндә колакларым кызарып, битләрем яна башлаган иде инде. Кеше алдында оятка калмас өчен сезгә дә әйтәм. Теркәп барыгыз! Тоник алтын төстәге көрән – бусы булды бер! Икенчесе – ком бураны төсе, өченчесе – фазан төсе, төлкекөрән, ясалматаш төсендәге көрән, штукатуркөрән, хәтта тутыккан гайка төсендәге көрәне дә бар иде. Бу минем исемдә калганнары гына. Йа Аллам, нигә соң мәктәптә укыганда миңа салават күперендә җиде төс бар дип кенә өйрәттеләр? Нигә?

Ясалма асылташ төсле көрән каләм белән машинага чыгып утырдык… Татарның акылы төштән соң бит. Каләмнең чегын ачып карадым. Йа Аллам, ник? Ник карадым мин аны? 40 сумлык каләмне 340 сумга алганбыз… Машина парковкада торган өчен 200 сум. Барып кайту, бензины, «бөке»ләр белән исәпкә алганда 500 сум. Һәм сәгать ярымлык оят. Кайнап чыккан чәйнек кебек хатыныма борылып карадым.

Ә тормыш чәчәгем алтын балык эләктергәндәй ике куллап тоткан каләменә карап утыра. Шатлыгыннан шартламый гына инде… Ничек яратмыйсың бу күктән төшкән бәхетне? Күтәрелеп, кызыл утка карадым. Ярый әле светофорны Джон Пик Найт дигән ир-ат уйлап тапкан. Берәр хатын-кыз уйлап тапкан булса, куе чия кызыл төсендә басып торыр идек, кызыл хризантема төсендә әзерләнер идек тә, алсу кызыл төскә кузгалыр идек…

Әз-мәз мәзәк

Балыкчылар чемпионатын җиденче көнгә наркологлар килеп куып тараткан.

* * *

Хәзер лаеклы ялга чыгуны ирләр ике тапкыр бәйрәм итәчәк. 60 яшьтә – иске, 65 яшьтә – яңа стиль буенча.

* * *

Чыгарылыш кичәсендә Русланның хыялы һәм Алинәнең әнисенең куркулары берьюлы чынга ашты.

* * *

Кибеткә кергән идем, чыннан да, берни юк: карабодай да, шикәр комы да, бәрдәф кәгазе дә. Гауга куптарган идем, куып чыгардылар. Йорт җиһазлары сата торган кибет икән бу.

И	Т	Ә	М	И	Т	Й
Я	Т	К	Ә	Ш	Ы	А
С	Ә	Ә	Л	Ә	Р	М
Т	Ү	П	И	К	Ә	Ә
Ә	Ш	А	М	Й	М	А
М	Л	Р	К	А	К	К
С	К	И	М	О	Н	О

ШАКМАКЛАРДАГЫ ТИЕШЛЕ СҮЗЛӘРНЕ ТАП. ҖӘЯ ЭЧЕНДӘ ХӘРЕФЛӘР САНЫ БИРЕЛГӘН.

Түбәтәй (7). Хоккейчы кулында (6). «…ләрем, …ләрем, сез минем сердәшләрем» (5). Юморист Рәшит (6). Сөттән аералар (6). Җырчы Разакова (6). Татар «божья коровкасы» (5). Идәнгә параллель (5). «Шаян» Сәхәбетдинова (6). Тузикның дусты (5). «Җәвит-…» (5). Дзюдочы халаты (6). Инглиз катнашмасы (4). Татарның каймагы (5). Шамкай (5). Кияүне култыклаган (5). Аның өстенә басма (5). Мунчада аны үзең юып булмый (4). Искиткеч хәл (6). Тәти эт (6). Дус-… (2). Апрель дәвамчысы (3). Хуҗа Насретдин «каршеринг»ы (4). Төнге намаз (4). Чит (2). Юбка (4). Хәбәрнең дусты (2). Батыр җилкәсендә (4). Италия башкаласы (3). Курамшин (5). Флаг (4). Монасыйпов (5). Конвертка ябыштырганчы, артын ялыйлар (5). Ясалма чәч (5).

Җаваплары: кәләпүш, кәшәкә, миләш, Шамкай, каймак, Мәликә, камка, түшәм, Рамилә, Шарик, кәмит, кимоно, микс, мишәр, Рәшит, кәләш, тырма, арка, әкәмәт, маэмай, иш, май, ишәк, ястү, ят, итәк, ия, тәкә, Рим, Рамил, әләм, Шамил, марка, парик.

Дусларча шарж

Наил Галимов шаржы

Ул спортта да кирәк әйбер,
Сәхнәдә дә бик кирәк,
Шәп трамплиның булса әгәр,
Сикерерсең өскәрәк!

Венера апада укысаң,
Трамплиның да кирәкми,
Арттан бер чөеп җибәрсә,
Очарсың йолдыз кеби!



Абау! Мин гомерем буе сокны дөрес эчмәгәнмен икән!

Мач әйткән!

Рашат НИЗАМИ, язучы:
Карьераң булмаса – кар ера алмыйсың!

ИҢ ШӘП ШАШЛЫК РЕЦЕПТЫ

1 Шашлык ясаучы тирәсендә буталып йөрмәгез.

2 Аңа кирәкле-кирәксез киңәшләр бирмәгез.

3 Шампурларны әйләндерә күрмәгез!

4 Өстенә су сибә күрмәгез!

5 Кулга эләккән теләсә нәрсә белән җил кудырмагыз.

6 Һәм иң мөһим пункт: шашлык ясаучыны «әйдә тотыйк берне» дип урыныннан кузгатмагыз!

Шулай бервакыт...

ЭССЕ, НӘҖИБӘ АПА!

Танылган шагыйрә Нәҗибә Сафина йөгереп диярлек лифтка килеп керә. Ул вакытта лифтта инде бер-ике кеше була. Читкәрәк тайпылып, Нәҗибә апага урын бирәләр. Шагыйрә лифттагы кешеләргә карый да: «Жарко сегодня», – дип куя. Шунда берәү аны танып ала да: «Жарко гынамы соң! Эссе хәтта, Нәҗибә апа», – ди.

СИРАҖИ: «АЛЛАГА ШӨКЕР!»

Журналист Искәндәр Сираҗига дусты шалтырата:
– Сәлам!
– Сәлам, кәнишны!
– Ялда-фәлән, чит илдә түгелме? Сөйләшә аласыңмы?
– Ю-юк, эш тә эш, ял күренми әле монда.
– Аллага шөкер, мин генә түгел икән шундый!
– Сине дә хатының аптыратамы соң Төркиягә барыйк дип?
– Аптыратмаган кая инде!
– Аллага шөкер!

МАРАТ ЗАКИР «РОЛЕ»

Берзаман Казанда узган шигырь бәйрәмендә бик күп каләм әһелләре катнаша. Чара тәмамлангач, кайсы кая таралышалар. Язучылар Марат Закир белән Газинур Морат бәйрәмнән бәйрәмчә, бераз селкенебрәк кайтып килә. Машинасына утыртырга теләпме аларга бер хезмәттәшләре дәшә.
– Сез рульдәме? – дип сорый ул.
Шунда Марат Закир бик җитди генә итеп имән бармагын өскә күтәрә дә әйтеп куя:
– Без рольдә!

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6640 данә
Гомуми тираж – 16041 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 293

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+